Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советының унөченче утырышы

# КАРАР

22 октябрь, 2021 ел № 34

«Җир салымы турында» 2017 елның 16 октябрендәге 87 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. «Җир салымы турында» 2017 елның 16 октябрендәге 87 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт белән тулыландырырга:

«2.1. Җир кишәрлеге бер төрдән артык рөхсәт ителгән файдалануга ия булса, салым салу максатларында әлеге кишәрлек өчен билгеләнгән рөхсәт ителгән куллану төрләре буенча җир салымы ставкасының иң зур күләме «Җир салымы турында» авыл җирлеге карары белән билгеләнгән булуын билгеләргә.».

1.2. 3 пунктындагы 3.1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

3.1. Түбәнгерәк салым ставкасын куллану рәвешендә:

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән махсуслаштырылган оешмалар милкендәге җир кишәрлекләренә карата Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,001 %;

федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджеттан финанслана торган автоном, казна, бюджет учреждениеләренә, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга 0,07 % күләмендә;

1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,05 % күләмендә.».

2. Әлеге карарның 1.1 пункты, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның 1.2 пункты рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткергә).

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов